| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 19 сентябрь 2014 ел | Казан шәһәре | № 10-24/кс |

***Эчәргә яраклы су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу хезмәте өчен тарифларны билгеләү турында***

“Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында” 7 декабрь, 2011 ел, № 416-ФЗ Федераль законга, “Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салу” 13 май 2013 ел № 406 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 ел 468 №лы карары белән расланган карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызучы оешмалар өчен, эчәргә яраклы су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу хезмәте өчен тарифларны, әлеге карарның кушымтасына таянып билгеләргә.
2. Түбәндәге карарның 1нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 01 ноябереннән 2014 елның 31 декаберенә хәтле үз көченә ия була.
3. Россия Федерациясе Хөкүмәте 17 гыйнвар 2013 елгы, № 6 карары белән расланган, ирекле кулланышка кертелергә тиешле, су белән тәэмин итү һәм һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә информацияне ачу стандартларына нигезләнеп, әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызучы оешмаларга, алдагы җайга салу чорына тарифларны билгеләү турында нәтиҗәгә килгәч, 30 календарь көннән дә соңга калмыйча информацияне ачырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
кушымта
19 сентябрь 2014 ел № 10-24/кс

## Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызучы оешмалар өчен, эчәргә яраклы су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу хезмәте өчен тарифлар

| № п/п | Салкын су белән һәм ташландык суларны агызуны тәэмин итүче муниципаль берәмлек, оешма исеме | Эчергә яраклы су тарифы (берставкалы), сум/куб.м | Ташландык суларны агызу тарифы (берставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | | 1 ноябрь 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел | 1 ноябрь 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел |
| | Баулы муниципаль районы | | |
| 1 | ЖЧЖ «Водоканал»* | 28,24 | 17,71 |
| | Чирмешән муниципаль районы | | |
| 2 | МУП «Чирмешән районы коммуналь челтәре»* | 22,85 | 37,83 |

<*> гадиләштерелгән салым алу системасы кулланыла

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештуры һәм җайга салу бүлеге